КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 10 май г.Казань № 6-875

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2021 елның 26 июненнән 27 июненә кадәр һәм 21 июленнән 22 июленә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «Ефәк юл» халыкара раллиенда (алга таба – Ралли) катнашучыларны озатып йөрү һәм вакытлыча урнаштыру чараларын оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә «Ефәк юл» халыкара раллиенда катнашучыларны озатып йөрү һәм вакытлыча урнаштыру чараларын оештыру буенча оештыру комитеты составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә Раллида катнашучыларга аларның вакытлыча булу урыннарында шартнамә нигезендә медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы территориясендә Раллида катнашучыларны озатып йөрү һәм вакытлыча урнаштыру чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә Раллида катнашучыларның вакытлыча булу урыннарында хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне саклауны тәэмин итүдә булышлык күрсәтүне;

Татарстан Республикасының Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетына Раллида катнашучыларның Бөгелмә шәһәрендә вакытлычы булуы һәм урнашуы буенча чаралар оештыруда, шул исәптән мәдәни-спорт чараларын оештыруда ярдәм күрсәтүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Раллида катнашучылар яшәгән һәм тукланган урыннарда санитария-

эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында тиешле чаралар үткәрүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә Раллида катнашучыларның вакытлыча булу урыннарында янгын куркынычсызлыгы чаралары үтәлешенә күзәтчелекне тәэмин итүне.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 10 май, б-875 нче
боерыгы белән расланды

2021 елның 26 июненнән 27 июненә кадәр һәм
21 июленнән 22 июлена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә
«Ефәк юл» халыкара раллиенда катнашучыларны озатып йөрү һәм вакытлыча
урнаштыру чараларын оештыру буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Чагин Владимир Геннадьевич | «Ефәк юл» халыкара раллие» проекты җитәкчесе, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциягә карамаган партнерлыгы директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абусев Азат Габдулла улы | «Ефәк юл» халыкара раллие» проекты җитәкчесе урынбасары – әлеге проектны урнаштыру буенча директор, «Ефәк юл» раллиеның төбәк дирекциясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Авдонина Любовь Геннадьевна | Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Егоров Иван Михайлович | «Татарстан Республикасының Автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Закиров Линар Рөстәм улы | Татарстан Республикасының Бөгелмә муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Садриев Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |